**Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәрнамә**

Әлеге мәгълүмат белән Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» боерыгы проекты буенча, атап әйткәндә, Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Апас, Чирмешән а. п., Багыш, Үзәк урам, 1Б з/у адрес буенча урнашкан кадастр номеры 16:08:200201:787, мәйданы 2022 кв. м булган җир кишәрлегеннән файдалануның Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең универсаль торак зонасында (Ж-У) «Дини йолаларны гамәлгә ашыру», «Дини идарә һәм мәгариф» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гавами тыңлаулар башлануы хакында хәбәр итәбез.

Проектка кертелгән мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) 1 нче фото – Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Чирмешән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир төзелеше һәм төзелеш кагыйдәләреннән өземтә;

2) 2 нче фото – Универсаль торак зона (Т-К);

3) 3 нче фото – Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең генераль планы;

4) таблица – Шәһәр төзелеше регламентлары.

Проект буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм сроклары:

Проект буенча җәмәгать тыңлаулары 2026 елның 2 сентябреннән 2026 елның 16 сентябренә кадәр үткәрелә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:

Проект әзерләнгән җир кишәрлеге урнашкан чикләрендә даими яшәүче гражданнар;

шушы территориаль зона чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

проект әзерләнгән җир кишәрлегенә якын җир кишәрлекләре чикләрендә даими яшәүче гражданнар;

мондый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

проект әзерләнгән капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре;

җир кишәрлегенең яки капиталь төзелеш объектының шартлы рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта – мондый тискәре йогынты куркынычы янаган җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре.

Проект әзерләнгән территория:

Кадастр номеры 16:08:200201:787 булган, мәйданы 2022 кв. м тәшкил иткән җир кишәрлеге. Адресы: Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Чирмешән авыл җирлеге, Багыш авылы, Үзәк урам, 1Б йорт кишәрлеге.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы:

Багыш авыл мәдәният йорты бинасы. Адресы: Татарстан Республикасы, Апас районы, Багыш авылы, Яшел урам, 21А йорт. – 2026 елның 2 сентябре.

Проект экспозициясен (экспозицияләрен) үткәрү сроклары:

2026 елның 2 сентябреннән 2026 елның 16 сентябренә кадәр

Экспозициягә (экспозицияләргә) килү мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:

Эш көннәрендә сәгать 9.00 дән 16.00 гә кадәр, төшке тәнәфес – 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тарафыннан проектка карата тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы:

2026 елның 2 сентябреннән 2026 елның 16 сентябренә кадәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ШтК) 12 өлеше, 5 маддәсе нигезендә идентификация узган җәмәгать тыңлауларында катнашучылар әлеге проектка карата тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышы яисә җыелышларын үткәрү барышында язма рәвештә яисә телдән;

2) язма формада яки электрон документ формасында җәмәгать тыңлауларын оештыручыга – оештыру комитетына 422350, Татарстан Республикасы, Апас районы, штп Апас, Совет урамы, 2 нче йорт адресы буенча (җәмәгать тыңлаулары буенча оештыру комитеты) яки apast@tatar.ru электрон почта адресы буенча;

3) җәмәгать тыңлауларында каралачак проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) язма калдыру юлы белән.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышын (җыелышларын) үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:

2025 елның 17 сентябре, Мәскәү вакыты белән 17.15 сәгатьтә. Татарстан Республикасы, Апас районы, Багыш авылы, Яшел урам, 21А йорты.

Җәмәгать тыңлауларында каралачак проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайты: https://apastovo.tatarstan.ru/, «Район турында/Авыл җирлекләре/Чирмешән авыл җирлеге/Җәмәгать тыңлаулары» бүлегендә.

Әлеге хәбәрне Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (инфраструктура үсеше буенча) — А.М. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече — А.В. Нурмиева

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы

Советының бишенче чакырылыш депутаты А.Т. Зиннәтуллин

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлек башлыгы Э.Ф. Шакирова

Апас муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Г.М. Сибгатуллина

